**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Бирючевка авылы № 4 15 март 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 24ноябрь 107 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (2015 елның 18 августындагы 131 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 11 номерлы, 26 апрель 2018 елнын 93 номерлы ,2018 елның 13ноябрендәге 112 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 119 номерлы, 2019 елның 25 июнь 137 номерлы карарлар редакциясендә)

"Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 23 декабрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрь 107 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (2015 елның 18 августындагы 131 номерлы, 2015 елның 28 октябрендәге 11 номерлы, 2018 елнын 26 апрель 93 номерлы , 2018 елның 13 ноябрендәге 112 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 119 номерлы, 2019 елның 25 июнь 137 карарлар редакциясендә) ,3.2 пунктындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасы бирү турында гариза бирмәгән яисә салым ташламасын кулланудан баш тарту турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы һәм салым түләученең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап салым органы тарафыннан алынган белешмәләр нигезендә бирелә."

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай

муниципаль районының Интернет- мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга: http://aznakayevo.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: В.В.Крашенинников